РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 27 мае Кукмара ш. № 125

«Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турында» Кукмара район Советының 2010 елның 26 мартындагы 14 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә, Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибен билгеләү максатыннан, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара район Советының 2010 елның 26 мартындагы 14 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (Кукмара муниципаль район Советының 15.08.2012 елның 15 августындагы 149 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

14. «Даими яшәү урыныннан читтә (тәүлеклек) яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар хезмәткәргә хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен, ял һәм бәйрәм көннәрен дә, шулай ук юлда булган көннәрне дә кертеп, шул исәптән юлда мәҗбүри тукталыш вакыты өчен дә Татарстан Республикасы чикләрендә 200 сум күләмендә, Татарстан Республикасыннан читкә командировкада 350 сум күләмендә (Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләреннән тыш) һәм Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләренә командировкада булган вакытта 700 сум күләмендә түләнә.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев